РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН ГЛАВА ГАЙТАНКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ГАЙТӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

423014, РТ, Нурлатский район, с. Гайтанкино, ул. Садовая, дом 17,
Тел. 8 (84345) 3-98-01

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» октябрь 2023 ел № 4

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Кара Күл авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гэйтэн авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 1 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Лесная урамы 7нче йорт адресы буенча урнашкан ФАП бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Кара Күл авылында Лесная урамы 1-32нче, Озерная урамы 2-24нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлегенең Кара Күл территориясендә теркәлгән һәм яшәүче балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 11000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?:

1. Кара Күл эчендәге юлларны карап тоту һәм грунт катнаш таш җәеп ремонтлау, шул исәптән төзелеш контроле өчен түләүне дә кертеп сезонлы карап тоту.
2. Кара Күл торак пунктында күперне ремонтлау.
3. Кара Күл торак пунктында скважинаны бораулау һәм суүткәргеч төзү, күзәтү коелары һәм янгын гидрантлары төзү.

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/rus/nurlat_poselenia.htm, бастырып чыгарырга, Татарстан

Республикасы Нурлат муниципаль районы Кара Күл торак пунктының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Гайтән авыл җирлеге башлыгы Н. В. Авдеева